**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**12 нче октябрь, 2022 ел** **№ 212**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләрнең күләмнәрен, һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлек башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы, сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының айлык акчалата бүләкләүләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләрнең күләмнәрен, һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карары (23.09.2020 № 4, 12.11.2021 № 122 һәм 31.03.2022 № 156 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының айлык акчалата бүләкләүләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкыр арттырырга.

2. Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләрнең күләмнәрен, һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220

номерлы карары (23.09.2020 № 4, 12.11.2021 № 122 һәм 31.03.2022 № 156 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән каралган тәртиптә билгеләнә торган муниципаль хезмәтнең алар биләгән вазыйфалары нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән арттырырга.

3. Әлеге Карарның 2 нче пункты нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләмен 1,04 тапкырга индексацияләргә һәм аны 11958 сум күләмендә билгеләргә.

4. 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарның «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфалар биләүче затларга, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының контроль-хисап органы рәисенә хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары» 1 нче кушымтасындагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 төркем |
| Муниципаль район башлыгы | 31660 |
| Муниципаль район башлыгының урынбасары | 28494 |
| Муниципаль районның контроль-хисап органы рәисе | 28494 |

5. 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарның «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре» 2 нче кушымтасындагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| N т/б | Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|---|
| | | 8 төркем |
| 1. | Башкарма комитет җитәкчесе | 31091 |
| 2. | Совет аппараты җитәкчесе | 28221 |
| 3. | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 27982 |
| 4. | Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 27862 |
| 5. | Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 25590 |
| 6. | Башкарма комитет аппараты (эшләр идарәчесе) җитәкчесе | 26188 |
| 7. | Башкарма комитет аппараты идарәсе башлыгы | 22720 |
| 8. | Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе | 20927 |
| 9. | Башкарма комитет аппаратының идарә башлыгы урынбасары | 21524 |

| | | |
|---|---|---|
| 10. | Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары, Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 19013 |
| 11. | Муниципаль район башлыгы ярдәмчесе | 19013 |
| 12. | Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек җитәкчесе | 19013 |
| 13. | Сектор җитәкчесе | 17578 |
| 14. | Баш белгеч | 16861 |
| 15. | Әйдәп баручы белгеч | 15665 |

6. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http//vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Биектау муниципаль районы Советының бюджет, финанс һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль районы Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов